КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 14 апрель г.Казань № 248

2021 елның 29 мартында Зеленодольск шәһәрендә булган күпфатирлы торак йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү турында

2021 елның 29 мартында Зеленодольск шәһәрендә булган күпфатирлы торак йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына бер тапкыр матди ярдәм түләүне башкарырга:

2021 елның 29 мартында Зеленодольск шәһәрендә булган күпфатирлы торак йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә һәлак булучыларның (вафат булучыларның) гаиләләре әгъзаларына (хатынына (иренә), балаларына, ата-аналарына һәм тәрбиясендә булган затларга) - гаиләнең һәр әгъзасына тигез өлешләрдә һәм һәлак булучга (вафат булучыга) 1 000,0 мең сум күләмендә;

2021 елның 29 мартында Зеленодольск шәһәрендә булган күпфатирлы торак йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә сәламәтлеккә зыян алган гражданнарга:

сәламәтлеккә авыр зыян булганда - бер кешегә 300,0 мең сум күләмендә;

сәламәтлеккә уртача зыян килгәндә - бер кешегә 200,0 мең сум;

сәламәтлеккә җиңел зыян булганда - бер кешегә 100,0 мең сум;

беренче ихтыяҗның милкен югалткан гражданнарга беренче ихтыяҗның өлешчә югалган мөлкәте өчен исәпләгәндә - 50,0 мең сум күләмендә, беренче ихтыяҗның тулысынча югалган мөлкәте өчен - 100,0 мең сум күләмендә.

Әлеге пунктның икенче - җиденче абзацларында күрсәтелмәгән 2021 елның 29 мартында Зеленодольск шәһәрендә булган күпфатирлы торак йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм бер кешегә 10,0 мең сум күләмендә түләнә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары булуын билгеләргә.

3. Зыян күрүчеләргә оператив ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге карарның 1 пункты нигезендә «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча «2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2020 елның 27 ноябрендәге 78-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган акчалар исәбеннән бер мәртәбә матди ярдәм түләүне башкарырга рөхсәт итәргә.

Карарга теркәлгән 2021 елның 29 мартында Зеленодольск шәһәрендә булган күпфатирлы торак йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга бер тапкыр матди ярдәм күрсәтү тәртибен расларга.

5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы башлыгына М.П.Афанасьевка 2021 елның 29 мартында Зеленодольск шәһәрендә булган күпфатирлы торак йортта газ-һава катнашмасы шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнар тарафыннан милекне югалту дәрәҗәсен бәяләү тәртибен әзерләүне һәм раслауны, шулай ук 2021 елның 29 мартында Зеленодольск шәһәрендә булган күпфатирлы торак йортта газ-һава катнашмасын шартлау нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга беренче кирәкле мөлкәтне югалту дәрәҗәсе турындагы белешмәләрне әзерләүне һәм раслауны атна дәвамында тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин